Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

13.12.2022 _______________Менделеевск ш. № 779_______

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Менделеевск шәһәре территориясендә
пиротехник эшләнмәләр (фейерверклар)
куллануны тәртипкә салу чаралары турында

«Пиротехника әйберләрен таратканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 22 декабрендәге 1052 номерлы карарына таянып, халыкның гомерен һәм сәламәтлеген яклау, муниципаль мөлкәткә, юридик һәм физик затларының мөлкәтенә зыян китерүне булдырмау максатларында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ

1.1. Менделеевск шәһәре территориясендә әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә пиротехник эшләнмәләр (фейерверклар) җибәрү мәйданчыкларын расларга;
1.2. Фейервеклар куллануны тыярга:
- теләсә кайсы функциональ билгеләнештәге бүлмәләрдә, биналарда һәм корылмаларда, шул исәптән якындагы территорияне дә кертеп;
- шартлату куркынычы булган һәм янгын куркынычы янаган объектлар, җитештерү предприятиеләре территорияләрендә, тимер юлларны, нефть үткәргечләрне, газүткәргечләрне, югары вольтлы электр линияләрен, вокзалларда, барлык төр җәмәгать транспортында читләштерү полосаларында, шулай ук әлеге объектлар чикләреннән 500 м дан якынрак булмаган урыннарда;
- балалар, уку, дәвалау-профилактика һәм фәнни учреждениеләр янәшәсендәге территорияләрдә, шулай ук әлеге объектлар чикләреннән 50 метрдан да якын түгел;
түбәләрдә, балконнарда, лоджияларда, бина (корылмалар) фасадларының чыгып торган өлешләрендә, сәхнә мәйданчыкларында, стадионнарда һәм башка спорт корылмаларында;

- митинглар, демонстрацияләр, пикетлар уздырганда;
- пиротехник эшләнмәләр җитештерүче тарафыннан билгеләнгән яшь чигенә җитмәгән затлар тарафыннан.
- "Гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында" 2013 елның 26 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә төнге вакытта.
- урман массивларыннан 1000 метрдан кимрәк ераклыкта идарә ителми торган, очып китү принцибы конструкция эчендәге һаваны ачык ут ярдәмендә җылытуга нигезләнгән янучан материаллардан эшләнмәләр җибәрергә,

1.3. Фейерверк оештыру һәм аттыру мәйданчыгы әлеге карарның 2 нче номерлы кушымтасында бирелгән таләпләргә туры килергә тиеш;

1.4. Менделеевск шәһәре территориясендә III һәм аннан да югарырак хәвеф-хәтәр класслы пиротехник эшләнмәләр кулланып фейерверк җибәрү тыела.

1.5. Менделеевск шәһәре территориясендә фейерверклар вәкаләтле орган рөхсәте белән генә оештырыла

1.6. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты исеменнән фейерверклар (салютлар) урнаштыруга гаризалар карауны һәм рөхсәт бирүне гамәлгә ашыручы вәкаләтле орган тарафыннан Менделеевск муниципаль районының Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясен билгеләргә;

2. Район Советының мәгълүмати технологияләре белән тәэмин итү бүлегенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән административ регламентларны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә: www.mendeleevsk.tatar.ru

2.1. Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш бүлеге (алга таба - Менделеевск МР буенча КЭ һәм ПЭБ):

-үз вәкаләтләре кысаларында халыкка массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка каналлар аша Менделеевск шәһәре территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары турында хәбәр итүдә, шулай ук янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә аңлату эшләре алып баруда катнашырга;

- гамәлдәге законнар кысаларында әлеге карарның 1 нче номерлы кушымтасында күрсәтелгән оештырылган мәйданчыкларда фейерверк җибәрү урыннарының әзерлеген тикшерүне оештырырга.

2.2. Менделеевск районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлегенә, Менделеевск районы буенча ведомстводан тыш саклау бүлегенә:

- Менделеевск шәһәре территориясендә фейерверкларны санкцияләнмәгән җибәрүне туктату буенча кирәкле ярдәм күрсәтергә;

- гражданнарның һәм мөлкәтнең тормышын һәм сәламәтлеген саклауны берсүзсез тәэмин итү буенча тулы хокукый һәм оештыру чараларын кабул итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасары С.В. Метальниковка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Искәндәров

КИЛЕШТЕРЕЛГӘН:

Шәһәр хуҗалыгы буенча
җитәкче урынбасары С.В. Метальников

Юридик бүлек башлыгы Е.С. Царева

.

Татарстан Республикасы<br>Менделеевск муниципаль районы<br>Башкарма комитетының<br>2022 елның _______<br>1 номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында пиротехник эшләнмәләр (фейервер күрсәтүләре) куллану мәйданчыклары

1. «Дуслык» бакча җәмгыятьләре һәм Чоловский урамы арасындагы болын кырларындагы мәйдан.

2. Менделеевск шәһәре чикләрендә Кама елгасы акваториясе.

3. Башка мәйданчыклар, контроль органнары белән килештереп, пиротехник эшләнмәләрдән файдалану мәйданчыкларына таләпләр нигезендә.

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның _______
2 номерлы кушымта

Менделеевск шәһәрендә
пиротехник эшләнмәләр куллану мәйданчыгына таләпләр

1. Фейерверк үткәрү мәйданчыгы чикләре әйләндереп алынган һәм янгын сүндерүнең беренчел чаралары белән тәэмин ителергә тиеш.
Биналарга һәм корылмаларга кадәр куркынычсыз ераклыкны күздә тотып, куркынычсыз зона чикләрен күрсәтелгән, фейерверк урнаштыру пунктлары билгеләнгән урын схемасы ясалган (схеманың зурлыгы А1 форматыннан кечерәк булырга тиеш түгел).
3. Тамашачылар җил уңаенда булырга тиеш. Эшләнгән схема нигезендә пиротехник эшләнмәләрне урнаштырганда җилнең тизлеге секундына 10 метрдан артмаска тиеш.
Фейерверк үткәрү урыннарыннан биналарга һәм тамашачыларга кадәр куркынычсыз ераклык кулланыла торган пиротехник эшләнмәләр инструкциясе таләпләрен исәпкә алып билгеләнә;
Мәйданчыкларда тәмәке тарту һәм ут кабызу, шулай ук пиротехник эшләнмәләрне караучысыз калдыру тыела.
Пиротехник эшләнмәләрне кулланганнан соң, территория тикшерелергә, файдаланган, атылмый калган пиротехник эшләнмәләрдән һәм аларның куркыныч элементларыннан чистартылырга тиеш.
Фейерверкларны урнаштырганда урыннарны саклау һәм куркынычсызлык өчен җаваплылык фейерверк үткәрә торган затка (оешмага) йөкләнә.
7. Мәйданчык территориясе, шулай ук мәйданчык чикләреннән 30 м радиустагы территория елның теләсә кайсы вакытында янучан материаллардан чистартылырга тиеш.